ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 3-05-44, факс: (84379) 3-05-44.

30 №

На № от

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авыл территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме: - Ленин урамыннан Чернышевский урамына кадәр суүткәргеч төзү, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 10 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 28 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 28 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 28 катнашучысы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясенең бер өлешендәге гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөресдип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авыл территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме: - Ленин урамыннан

Чернышевский урамына кадәр  суүткәргеч төзү, дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев